**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**2018 елның 29 мае** **№ 84**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» 2017 елның 22 августындагы 61 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге советының 2017 елның 22 августындагы 61 номерлы карары белән расланган Кече Салтык авыл җирлеге советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары биналарда, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук йорт эчендәге территорияләрдә уздырыла. Бу очракта аларны үткәрү тормыш-яшәешне тәэмин итү, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә объектлары эшчәнлеге бозылуга, җәяүлеләр һәм (яисә) транспорт чаралары хәрәкәтенә комачаулар булдыруга йә гражданнарның торак урыннарына яисә транспорт яисә социаль инфраструктура объектларына керүенә китермәскә тиеш. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының яисә җирле үзидарә органнарының мондый очрашулар турында хәбәре таләп ителми. Шул ук вакытта депутат күрсәтелгән органнарга аларны уздыру датасы һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хокуклы.

Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннар, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бирелә торган биналар исемлеге һәм аларны бирү тәртибе Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Бистә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

Депутатның гавами чара рәвешендә сайлаучылар белән очрашулары җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә.»

1.2. «Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр» 11 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр

1. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы идарәсендә яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре идарәсендә, сәяси партия катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш), федераль законнарда каралган очраклардан тыш, һәм оешма идарәсендә катнашу җирле үзидарә органы исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш;

2) укытучы, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Бу очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яки Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, укыту эшчәнлеге, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек чит дәүләт, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына финанслана алмый;

3) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә;

4) граждан, административ яисә җинаять эше буенча яки административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнашырга.

2. Депутат «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш.».consultantplus://offline/ref=A27132B34C0D7D554EA10C985C99CE2D836A38091FBB62267DC09B5EFFlEK2Lconsultantplus://offline/ref=A27132B34C0D7D554EA10C985C99CE2D8063300A1CB962267DC09B5EFFlEK2L

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче ур., 9 йорт, Мәдәният йорты бинасы;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мереткозино авылы, Вахитов ур., 9, авыл китапханәсе мәдәният йорты бинасында урнаша, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе А.Г. Җиһаншин**